РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
УРМАНЧЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.5, п.Зверосовхоза,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРМАНЧЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ
Ленин ур., 5 нче йорт, Җәнлек совхозы поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422186

тел.(факс): (85563) 2-12-50; e-mail: Urman.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление Карар

№ 46 от “ 20 ” сентября 2017 г

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урманчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башкарма комитеты К А Р А Р БИРӘ:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2018 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. **Торак пункт чикләрендә су белән тәэмин итү, су чыгару оештыру**: Сотово торак пунктында, Берсут торак пунктында, Новый торак пунктында, Кама урман хуҗалыгы торак пунктында -3 шт., Женлек совхозы торак пунктында, Урманчеево торак пунктында- су алу скважинасын эйлэндереп алу; Женлек совхозы торак пунктында су алу манарасы урнаштыру.
2. **Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**

янгын гидранты җайланмасын сатып алу һәм урнаштыру:

Новый т.п.,Женлек совхозы т.п.,Урманчы т.п-

**3. Торак пункт территориясен төзеклəндерүне оештыру (шул исəптəн урамнарны яктырту, кече архитектура формаларын урнаштыру һəм тоту):**

Сотово торак пунктында ,Кама урман хуҗалыгы т.п., Новый т.п. урам яктырту лампаларын алыштыру.

Женлек совхозы торак пунктында «һəлак булган сугышчы –җирдəшлəргə» һəйкəлен төзү һəм урнаштыру.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берəмлек Советының мəгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мəгълүмат рəсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтəлешен Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башлыгы Р.Җ. Хəмизуллинга йөклəргə.

Мамадыш муниципаль районы
Урманчы авыл җирлеге
башкарма комитеты җитəкчесе Ильин А.Я.